**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6902**
**20.10.2021**

Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасының 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасының 1 нче кушымтасына, 34 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Сатып алына торган торак урын (шул исәптән өлешләп төзү объекты булып торган) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан булырга яки торак йорт төзелеше шунда гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Ф.Ш. Салахов